СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*

ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы карары**

**01 ноябрь 2024 ел** **N 10**

**Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш – Аты авылында Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 20 ноябренә 18 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 20 ноябренә 19 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Кооператив, Яңа урамнарда яшәүчеләр

2нче этап: Тарлау, 9 Май урамнарда яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

« Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Субаш-Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен асылмалы җайланмалар сатып алуны финанслау (роторлы кар чистарткыч );

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу, мини-төягеч хезмәтләре өчен түләү)?"

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Субаш - Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Утар - Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Субаш - Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы : Мөхәмәтгалиева А.Г.

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ